**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
Зеленодольский муниципальный район
**Исполнительный комитет Кугеевского сельского поселения**
ул. Мира, д. 22, с.Кугеево, 422516

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
Зеленодольск муниципаль районы
**Күгәй авыл җирлеге башкарма комитет**
Тынычлык ур., 22 нче йорт, Күгәй авылы, 422516

**КАРАР**

2021 елның 15 апреле №15

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә Күгәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 15.02.2021 ел, №4 карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күп функцияле үзәк тарафыннан күрсәтелмәү сәбәпле, Күгәй авыл җирлеге башкарма комитеты:

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының Күгәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 15.02.2021 ел №4 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. кисәк 6. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне)үтәү үзенчәлекләре-төшереп калдырырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында Яшел Үзән муниципаль районы рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Күгәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Күгәй авылы, Үзәк урамы, 29 йорт (җирлек администрациясе бинасында), Күгәй авылы, Тынычлык урамы, 20 йорт ( мәдәният йорты бинасы) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Күгәй авыл җирлеге башлыгы Ф.Х. Хисаметдинова